КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 апрель г.Казань № 262

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Баш ветеринария идарәсе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында көндәшлекне үстерү максатларының һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итә.»;

3.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« билгеләнгән тәртиптә төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге (03.02.04.3*).»;

3.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты белән – Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге функцияләрен тормышка ашырганда, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль әһәмияттәге аеруча саклана торган табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларыннан һәм аларның яшәү мохитеннән тыш (01.06.11.03*);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин